# 2018 елгы дөнья футбол чемпионаты буенча волонтерлар хәрәкәте




Эшләде: Ибраһимов Фәнзил
Төркем: 41108

Соңгы елларда «**волонтер**» исемле сүз киң тарала башлады. Волонтерлар турында күпләр ишеткән, ләкин аларның кем икәнен белмәүчеләр дә бардыр. Яшьләр арасында һәр икенчесе волонтер дисәк тә, дөрес булыр. Шулай да кем соң ул?







**Кем соң ул волонтёр?**

Волонтёр – ул ирекле кеше. Ул җәмәгать эшләрендә ирекле рәвештә, үз теләге белән шөгельләнә. Волонтёр һәрвакыт кешеләргә яхшылык, өмет һәм мәхәббәт таратучы булып тора.Чын волонтёр ул - әхлак тәрбияле ,кешелеклелек сыйфатларына ия булырга һәм башкалар белән уртак тел таба белергэ тиеш.

**Кыскача әйткәндэ волонтёрлык ул ГАИЛӘ!**




Волонтерлык илебезгә 1980-нче еллардан ук кереп китә, әмма ул аңарга кадәр дә булган иде – шәфкать туташлары, тимур һәм пионер хәрәкәтләре, табигать һәм һәйкәлләр саклау белән шөгыльләнгән җәмгыятьләр моңа ачык дәлил булып тора.

Хәзер аларның эзе бармы?

Татарстанда исә бу эш кайнап тора: спорт чараларында меңләгән студентлар, активистлар катнаша, республика күләм слётлар, лагерьлар, акцияләр үткәрелә. Ни әйтсәң дә, һәр волонтерда – чын, яхшылык тулы йөрәк!



Мин Ибраһимов Фәнзил Марат углы булам. Хәзер мин Идел буе Дәүләт Физик культура спорт хәм туризм академиясенең 4 курсында белем алам.

Кечкенә чагымнан ук мина волонтер хәрәкәте бик ошап килде. Мәктәптә булган куп волонтерлык чараларында катнаштым. Ә монда Казанга укырга килгәч тә шушы эшемне ташламадым. Күп кенә академия уздырган чараларда катнашам.









Иң зур мин катнашкан чаралар : Йөзү буенча дөнья чемпионаты 2015 ел ( «Казан Арена» футбол стадионында һәм Су спорт төрләре сараенда узды.)

Кубок Дэвиса 2016 ел (ярышлар безнең Теннис Академиясендэ үтте)

Кубок конфедерации 2017(безнен илебезнең 4 шәһәрендә узды, мин «Казань Арена» футбол стадионында һәм аэропортта эшләдем).











Конфедерация кубогы, 2017-милли җыелма командалары арасында, санау буенча, сигезенче тапкыр  үткәрелгән, футбол турниры. Ул 17 июньнән 2 нче июльгә кадәр, Рәсәйдә уздырылды. Конфедереция кубогы-2017, 2018 елда уздырылачак дөнья чемпионаты алдыннан үткәрелә торган «репетиция» туринры булып карала. Быелны бездә уздырылган ярышта Германия җыелма командасы җиңүгә иреште. Ул Чили җыелма командасын финал уенда1:0 исәбе белән отты.









2018 елда Футбол буенча дөнья чемпионаты узачак. Ул 21-нче дөнья чемпионаты. Футбол уеннары 14 июньнән-15 июльгә кадәр барачак. Рәсәй беренче тапкыр үз тарихында футбол ярышында ил-хуҗасы була. Моннан тыш, ул беренче тапкыр Көнчыгыш Европада үткәреләчәк. Чемпионатны уздыру Рәсәйнең 12 стадионында һәм 11 шәһәрендә узачак.




FIFA WORLD CUP
RUSSIA 2018


# 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионаты уздырылачак шәһәрләр:






Мәскәү

“Лужники” стадионы



Санкт-Петербург

“Санкт-Петербург” стадионы



Калининград

Арена “Калининград”

Волгоград



“Победа” стадионы

Түбән Новгород




“Түбән Новгород” стадионы

Ростов –на-Дону




“Ростов Арена”

Самара



“Самара Арена”

Казан




“Казан Арена”





Саранск



“Мордовия Арена”

Екатеринбург



“Екатеринбург Арена”

Сочи



Олимпиада стадионы “Фишт”

Мәскәү




«Стадион Спартак»

Футбол чемпионаты – бу иң әһәмиятле чараларның берссе спорт дөньясында. Аны оештыру матди чыгымнар һәм кеше байлыкларын  сорый. Иң мөһим звено булып ярышлар үткәрүдә – волонтёлар  торалар, чөнки алар төп социаль мәсьәләләрне хәл итәләр.

ФИФА волонтёрлары
Волонтёр булып төрле илнең гражданнары эшли ала. Конфедерация кубогын үткәрү өчен биш мең биш йөз волонтёр кирәк булды. Футбол буенча дөнья чемпионатына 15 мең волонтёр кирәк.

Волонтёрлар программасына 20 төрле юнәлешләр керә. Алар төрле күнекмәләрне таләп итәләр. Волонтёрлар сайлаганда , кандидатларның сәләтләре дә испкә алына, шулай ук волонтёрлык хәрәкәтендә катнашуы да соралырга мөмкин.

Спорт чараларында алынган тәҗрибәләрне  бер генә нәрсә белән дә чагыштырып булмый. Болар барысы да кеше алдында зур мөмкинлекләр ачалар.

Мин узем дә шушы ярышта волонтер булып эшләрмен дип уйлыйм. Волонтер булу ул бик куңелле, истәлектә кала торган вакытлар.Төрле илдән килгән кешеләр белән аралашасың, яңа дуслар табасың, чит телләр өйрәнәсең, спортсменннарны үз күзен белән курәсен, сиңа күп төрле истәлекле буләкләр тапшыралар һәм башка плюслары бик күп.







Волонтерлык — уникаль мөмкинлек тормышны үзгәртергә, шул исәптән, уңай якка. Ә иң мөһиме волонтер булып, тәҗрибә, кызыклы танышулар, якты хисләр һәм чагыштыргысыз тәэсирләр аласың. Волонтёрларның уңай энергияләре спорт чараларын чын бәйрәмгә әйләндерә.

Син дә волонтерлар рәтенә бас! Ул сиңа бердәмлек, зур уңышларга ирешергә мөмкинлек бирер.












RUSSIA
2018




# *Тыңлавыгыз очен рәхмәт!*

# Учись побеждать!

# *Learn to win!*

